| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**СОВЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы**<br>**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 14.07.2022 года | № 12 |

**Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында**

“Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабре 230-ФЗ номерлы Федераль законына туры китерү максатларында, Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Сарман муниципаль районы “Мортыштамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 22 август 12 нче номерлы карары белән расланган «“Мортыштамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырылган мәгълүматны “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру, бастыру өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәреш кертергә:
- 3нче пунктның “г” пунктчасында “, акцияләр” сүзен төшереп калдырырга.

2. Сарман муниципаль районы "Мортыштамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 19 июль 21нче номерлы карары белән расланган “Сарман муниципаль районы “Мортыштамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазифаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары рәсми сайтларына урнаштыру һәм бастыру өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә” үзгәреш кертергә:
- 2нче пунктның «[illegible]» пунктчасында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы — И.Н.Һадиуллин